• ӘҢГӘМӘ •
СИХЕР ЗОЛЫМЫННАН САК БУЛЫГЫЗ!
*3 бит*

• СПОРТ •
БЕРЕНЧЕ МӨСЕЛМАННАР ШӨГЫЛЬЛӘНГӘН СПОРТ ТӨРЛӘРЕ
*7 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
ЯҢА ЕЛ – НӘТИҖӘЛӘР ЯСАУ ВАКЫТЫ
*11 бит*

• ҖӘДВӘЛ •
“АЗАН” РАДИОСЫ ТАПШЫРУЛАРЫ ҖӘДВӘЛЕ
*15 бит*


*№ 8 (289)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *Зөлхиҗҗә 1440*

*Август, 2019*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Хаҗилар изге сәфәрдән кайталар!



Изге юлда – изге сәфәр. Хаҗиларыбыз исән-имин туган якларына кайталар. 21 август көнендә Мәскәү вакыты белән сәгать 01.00 дә Казанга Татарстан хаҗиларының беренче төркеме кайтты.

*Дәвамы 2 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Татарстан хаҗилары Казанга кайта башлады

*Дәвамы, башы 1нче биттә*



Күркәм гадәт буенча Казан аэропортында аларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. 87 кешенең барысы да Диния нәзарәтенең «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми хаҗ операторы программалары аша хаҗ кылган. Гомумән, 2019 елда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте өчен 1800 урын бүлеп бирде.

Беренче төркем самолет белән баштa Мәдинәдән Истанбулга, аннары Казанга очты. Төркем җитәкчеләре булып казый, Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрданшин һәм Лениногорск имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Сингатуллин торды.

Үзенең сәламләү сүзендә Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин хаҗиларны котлап кына калмыйча, шушы олы сәфәрнең әһәмиятен дә аңлатып китте: "Хаҗ кылган кеше яңадан туган кебек була: ул үзенең гөнаһ капчыкларын бушата, күңелен чистартып кайта. Хәзер инде харамнан сакланып яшәргә кирәк. Раббыбыз хаҗларыгызны һәм корбаннарыгызны кабул итсен. Аллаһы Тәгалә безгә Аның Җәннәтләрендә бүгенгедәй шат булып очрашырга насыйп әйләсә иде".

Республика хаҗилары турларын Татарстандагы бердәнбер рәсми хаҗ-операторы «ДУМ РТ Хаҗ»ның 4 программасы буенча алган: Казаннан «Стандарт – барысы да кертелгән», «Супер эконом», Мәскәүдән «Супер эконом», «Стандарт минимум», бу программалар үз эченә туклану, яшәү, трансфер һәм очкыч белән барып кайтуны, шулай ук юридик, медицина һәм квалификацияле консультатив ярдәм күрсәтүне берләштерә.

Хаҗ сәфәрләрен оештырганда «ДУМ РТ Хаҗ» өчен иң беренче нәүбәттә хаҗиларның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре аеруча мөһим торды. Хаҗилар белән бергә 40 тәҗрибәле җитәкче һәм барлык кирәкле җиһазлары һәм медикаментлары булган төрле белгечлектәге 20 табиб (кардиологлар, терапевтлар, инфекционистлар һәм хәтта гинекологлар) барды, Татарстан хаҗилары өчен тәүлек әйләнәсе медицина пунктлары эшләде.

Шунысы мөһим, «ДУМ РТ Хаҗ» операторы Россиянең Хаҗ миссиясендә аккредитация узган һәм Бердәм федераль туроператорлар реестрына РТО 018911 номеры белән теркәлгән. «ДУМ РТ Хаҗ» кече һәм зур хаҗ оештыру буенча күпьеллык тәҗрибәгә ия һәм ислам диненең бишенче баганасын Хәнәфи мәзһәбе нигезендә имин һәм ышанычлы шартларда үтәүне гарантияли. Шунысы игътибарга лаек, Татарстан Россиядә мөселманнарны хаҗга хәнәфи мәзһәбе нигезендә әзерләүче бердәнбер төбәк булып тора. Хаҗилар шәригать канgranнары нигезендә тиешле гыйбадәтләрен дөрес башкарсын өчен төркем җитәкчеләре зур аңлату эшләре алып барды.

■ dumrt.ru

# Татарстан мөфтияте сезонны яшьләр өчен яңа проектлар белән ачып җибәрә

Һиҗри буенча яңа 1441 елны (31 августка керәчәк) Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте яшьләр өчен яңа проектлар белән каршылый. Сентябрь аеннан башлап мөселман егет һәм кызлар төрле дини программаларда катнашырга чакырыла.

Мисал өчен, яңа сезонда мөслимәләр арасында зур популярлык казанган "Женская гимназия" проектын 4 ел эчендә беренче ребрендинг көтә. Ул хәзер **«Яшь килен»** исеме астында эшлиячәк. Атамасы белән бергә концепциясе дә үзгәрде: мөслимәләр өчен 7 атна дәвамында берешәрләп укылган гадәттәге лекцияләр хәзер гаилә кыйммәтләрен ныгытуга юнәлтелгән тематик очрашуларга үзгәрәчәк. Алар тулысы белән шәригать һәм татар милли гореф-гадәтләр күзлегеннән чыгып никах темасының төрле мәсьәләләренә багышланачак. Очрашулар һәм видеодәресләрдә булачак һәм хәзерге яшь киленнәргә милли традицияләр – бәби чәе, бишек җыры, кыз озату һ.б., никахның дини һәм хокукый яклары, хатын һәм ирнең бурычлары һәм хокуклары, мәһәр һәм никах килешүе, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе кебек мәсьәләләр турында сөйләнәчәк. Моннан тыш, мөслимәләр милли ашлар әзерләргә, бала карарга, кунакларны каршыларга өйрәнә алачак. Спикерлар булып психологлар, юристлар, табиблар, галимнәр торачак. Курслар 26 сентябрьдән сәг.18.30да башланып айның һәр икенче атнасында Галиев мәчетендә булачак. Соңгы дәрес кызлар өчен аулак өй форматында 19 декабрьдә узачак. Проектта катнашу өчен яшь чикләве юк.

«Яшь килен»гә ике ысул белән язылырга мөмкин: беренчесе – https://clck.ru/He3Xi сылтамасы буенча гариза тутырырга, икенчесе – +7 (843)237-86-18 телефонына шалтыратырга.

Мөселман егетләренә исә аерым клуб оештырылды – ир-атлар өчен **«I'MAN»** проекты. Анда катнашучыларны туплау башланды инде. Бу яңа уникаль проект ир-атлар аудиториясенең күпсанлы сораулары буенча төзелгән. **"I'MAN"** ир-атлар проектының беренче очрашуы 11 сентябрьдә булачак. Әлеге проектта Ислам кысаларында шәхси һәм рухи яктан үсәргә әзер 18 яшьтән өлкәнрәк булган ир-атлар һәм егетләр катнаша ала. Аларны атналык очрашулар, җитди практикалар, спорт һәм бик күп яңа гыйлемнәр көтә. Очрашулар шулай ук Казанның Галиев мәчетендә узачак. Аларда көндәлек тормышның барлык өлкәләрен дә диярлек җайга салучы шәригать нормалары, Мөхәммәд галәйһиссәлам Сөннәте турындагы белемнәрне киңәйтү, чын мөселманга хас булырга тиешле әлакый сыйфатларны үстерү, шулай ук рухи авырулардан бушану ысуллары турында сөйләнәчәк. «I'MAN» проектында катнашу өчен https://clck.ru/HiPh6 сылтамасы буенча үтеп яки +7 (843) 237-86-18 телефоны аша язылырга мөмкин.




■ dumrt.ru

# Нәзарәтнең «Зәкят» фонды «Татнефть» ГАҖ гранты хисабына «Хәят» социальләшү үзәге эшчәнлеген киңәйтәчәк



20 августта Әлмәттә «Нефтьче» мәдәният сараенда социаль башлангычлар конкурсында җиңүчеләр өчен «Татнефть» Гаммәви Ачык Җәмгыятенең грантларын тапшыру тантанасы булды. Чарада ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, «Татнефть» компаниясе генераль директоры, грант комитеты рәисе Наил Маганов, Әлмәт муниципаль районы җитәкчесе Тимур Нагуманов, ТР муниципаль районнары башлыклары һ. б. катнашты.

«Татнефть» ГАҖ грантына башкалар арасында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды да ия булды. Шул рәвешле, фондка «Татнефть» тән 1 200 000 сум күләмендәге сертификат тапшырылды. Грант акчасы тулысы белән үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен «Хәят» үзәге эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлдереләчәк.

Иң беренче нәүбәттә грант хисабына «Хәят» үзәгендә авыру балалар тәрбияләүче гаиләләргә яңа социаль хезмәтләр күрсәтү өчен өстәмә белгечләр җәлеп итү планлаштырыла. Мисал өчен, күп мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, мөстәкыйльлеккә ия булмаган балалар өчен берничә сәгатьлек «бакчада» аларны шәфкать туташлары һәм социаль тәрбиячеләрнең профессиональ күзәтүе астында калдырып тору мөмкинлеген оештыру ниятләнә. Мондый башлангыч балаларның үзләренә социальләшү өчен өстәмә этәргеч булса, ата-аналарга исә эмоциональ яктан «янып бетүне» кисәтү өчен уңай чара булып торачак. «Хәят» үзәгенә килергә теләүчеләр +7 (843) 225-33-22 телефоны аша «Зәкят» хәйрия фонды белгечләренә мөрәҗәгать итә алалар.

«Хәят» үзәге - Татарстан өчен уникаль проект. Ул РФ Президенты гранты ярдәмендә 2017 елдан бирле тормышка ашырыла. Үзәк балаларның һәм аларның әти-әниләренең физик һәм психик сәламәтлеген күтәрү, «үзенчәлекле» балаларны һәм аларның ата-аналарын социальләштерү максатыннан оештырылган. Үзәк эшли башлаганнан бирле анда йөрүчеләрнең үсешләрендә уңай динамика күзәтелә. Аларның күбесе аралашырга, бер-берсе турында кайгыртырга, дуслашырга өйрәнде. Әлеге үзәккә тулы һәм тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнүче, шулай ук тәрбиягә алынган 3 яшьтән 27 яшькәчә инвалидлар йөри. Үзәккә даими йөрүчеләр арасында – ДЦП, аутизм, начар күрү, чукраклык, саңгыраулык һәм башка катлаулы авырулардан интегүче, үсешләрендә башка тайпылышлар булган сабыйлар. Узган сезонда «Хәят»кә 250 гә якын кеше йөрде. Үзенчәлекле балалар һәм аларның әти-әниләре өчен үзәккә йөрү бушлай.

■ dumrt.ru

# «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗ гаиләләр өчен Корбан ашы уздырды

16 нчы август көнне «Туган авылым» милли комплексында ТР Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды үз карамагындагы балалар өчен Корбан ашы оештырды. Корбан бәйрәменә багышлап уздырылган чарада барлыгы 250 кеше катнашты. Мәҗлескә ДЦП диагнозлы, аутизм белән авыручы сабыйлар, аларның әти-әниләре, ятимнәр, начар күрүчеләр, сукырлар, аз керемле һәм күп балалы гаиләләр җыелды. Мәртәбәле кунаклар рәтендә Татарстан мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, «Сәлах» мәчете имам-хатыйбы Тимергали хәзрәт Юлдашев һ.б.лар бар иде.

Мәҗлесне күп санлы җыр бәйгеләре җиңүчесе Тимур Фазлыев Изге Коръән аятьләре укып башлап җибәрде. Аннары «Зәкят» хәйрия фонды генераль директоры Булат Мәрданов бәйрәмне оештыруга өлеш кертүчеләргә, иганәчеләргә, волонтерларга һәм күп еллар дәвамында фонд белән хезмәттәшлек иткән барлык мәрхәмәтле кешеләргә рәхмәт белдерде.

Алга таба бәйрәм кунакларын Татарстан мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов сәламләде. Үзенең чыгышында ул мохтаҗлык сүзенең мәгънәсен аңлатты:

– Мөхәммәд Пәйгамбәр галәйһиссәлам корбан итен өч тигез өлешкә бүлергә киңәш итеп калдырган: бер өлешен гаиләгә калдырырга, икенчесен - туганнарга һәм күршеләргә өләшергә, өченче өлешен мохтаҗларга таратырга. Ә мохтаҗлык нидән гыйбарәт соң? Мохтаҗлык – ул матди як кына түгел. Без аралашуга, игътибарга да бик мохтаҗ.



Иң куркыныч рухи авыру – битарафлык. Шуңа күрә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер-беребезгә карата игътибарлы булуны да күздә тоткан.

Мәҗлес программасында «Голос дети» проекты финалисты Сәидә Мөхәммәтҗанова һәм Коръән хафиз Фазлетдин Замонов башкаруында нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырады. Моннан тыш, «Зәкят» хәйрия фонды канаты астындагы тагын бер сабый – Диләрә Хөснуллина кунакларны Коръән аятьләре укып сөендерде.

Үзенең хис-кичерешләре белән бәйрәмгә оныгы белән килгән Рөстәм абый Вәлиуллин уртаклашты:

– Без 13 яшьлек оныгыбызны тормыш иптәшем белән икәү тәрбиялибез. Онытыбызда – ДЦП. Аның әнисе – кызыбыз – вафат булды. Безгә күрсәткән ярдәмнәре өчен «Зәкят» хәйрия фондына бик рәхмәтлебез. Фонд оештырган мондый мәҗлестәз беренче тапкыр катнашуыбыз. Билгеле, бу төр очрашулар кирәк. Без башкалар белән аралашуга бик мохтаҗ.

Искәртеп үтик: Корбан бәйрәме көннәрендә «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларга социаль азыктөлек ярдәме күрсәтте. Мөфтияттән корбан итләре алучылар арасында – аз керемле һәм күп балалы гаиләләр, инвалидлар, ятимнәр, ялгыз өлкәннәр, шулай ук республиканың социаль учреждениеләре: хоспислар, интернатлар, мәдрәсәләр, хәйрия фондлары. Бәйрәмнең беренче көнендә бәйрәм күчтәнәчен – 1,5 тонна күләмендә корбан итен 500 мохтаҗ кешегә өләштеләр. Икенче көнне тагын 650 гаиләне 2 тонна корбан ите белән тәэмин иттеләр. Моннан тыш, 2 тонна итне республиканың социаль учреждениеләренә озаттылар. Әлеге оешмалар арасында: беренче балалар хосписы, А.Вавилова исемендәге Казан хосписы, акыл үсешендә тайпылышлар булган балалар өчен 1 нче мәктәп-интернат, «Диабетсыз тормыш» Идел буе профилактика үзәге, «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге, Яшел Үзән шәһәренең психоневрологик диспансеры, Инвалид балаларның әти-әниләренең «Забота» төбәкара иҗтимагый оешмасы. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: ит корбан чалган мөселманнардан да килеп ирешә. Шуңа күрә нәзарәтнең «Зәкят» фонды мохтаҗларга итне планлаштырганнан артыграк – 5 тонна түгел, ә 5,5 тонна күләмендә таратты.

■ dumrt.ru

# Сихер золымыннан сак булыгыз!

Күз тию, бозым, сихер кебек төшенчәләрне һәркем читтән генә булса да ишетеп белә. Берәүләр аңа ышанып, бу золымнан сак булуның мөһимлеген белеп яшәсә, икенчеләр, әлеге сүзләргә ышанмыйча, көлеп карый. Тик ничек кенә булмасын, сихер – хак һәм аның турында Коръәни Кәримебездә дә язылган.

**Нәрсә соң ул сихер, бозым, күз тию? Ул каян барлыкка килгән? Аларның куркынычы нинди? Күз тию белән сихернең аермасы нидә? Һәм бу афәтләрдән ничек сакланырга?**

Әлеге һәм башка сорауларга җавап эзләп «Саләх» мәчете имам-хатыйбы Тимергали хәзрәт Юлдашевка мөрәҗәгать иттек.

**– Тимергали хәзрәт, күпләр ышанырга теләмәсә дә, сихер, шактый киң таралган күренеш. Ул кайчан һәм ничек барлыкка килгән?**

Әйе, чыннан да сихернең килеп чыгышы, таралуының үз тарихы бар. Аллаһы Тәгаләнең, һәр пәйгамбәр килгәндә аңа сихерче дип әйттеләр, дигән аятенә игътибар итсәк, сихернең тарихы бик борынгыдан – Адәм галәйһиссәлам заманыннан ук килгәнен аңлыйбыз. Ләкин аның гыйлеме таралган вакыты башка чорга туры килә. Көннәрдән бер көнне фәрештәләр Раббыбызга мөрәҗәгать итеп: **«Йә, Аллаһыбыз! Без һәрдаим Сиңа гыйбадәттә, Сиңа тәсбих, тәһлил әйтеп, зекердә торабыз, әмма Синең адәмнәрең вакытларын Сиңа итагать кылмыйча, гөнаһ кылып уздыра»**, – диде. Бу сүзләреннән соң Аллаһы Тәгалә аларга: **«Әй, фәрештәләрем! Арагыздан икегезне сайлагыз. Мин аларга адәм кыяфәте биреп, аларны Җир йөзенә төшерермен»**, – диде. Алар үз араларыннан Газа һәм Газая дигән фәрештәләрне сайлап алдылар. Аллаһы Тәгалә бу фәрештәләргә адәм сыйфатлары һәм нәфес биреп, аларны Җир йөзенә төшерде. Риваятьләргә караганда, Җир йөзенә сыналыр өчен төшерелгән бу ике фәрештә адәм баласы кылган гөнаһларның берсеннән дә ерагая алмады. Көннәрдән бер көнне Аллаһы Тәгалә боларга мөрәҗәгать итеп: **«Сез бик күп гөнаһ кылдыгыз, инде хәзер сайлагыз: дөнья газабын биримме яки Ахирәт газабын күтәчәксезме?»** – диде. Әлбәттә инде, кайчандыр фәрештәләрдән булган бу затлар Ахирәт газабының бик көчле булуын исәптә тотып, Аллаһы Тәгаләдән үзләренә дөнья газабын бирүне сорадылар. Аларга бирелгән газап Бабил (Вавилон) шәһәрендә сихер дәресләрен укытудан гыйбарәт иде. Һәм алар, кешеләрне кисәтеп, безгә килә күрмәгез, безнең гыйлемгә иярмәгез, ул гыйлем белән кяфер булмагыз, диделәр. Әммә адәм балалары бу сүзләрне санга сукмады, сихер гыйлемен үзләштерергә ашыкты, алар арасында Аллаһының ләгънәтендә булган шәйтан да бар иде. Әлбәттә инде, ул бу эшкә начар ният белән ныклап тотынды. Ул үз алдына кешеләр арасын бозу, аларны хак юлдан яздыру, гөнаһка батыру һәм ахыр чиктә адәм балаларын җәһәннәмгә кертү максатын куйган иде. Бу хәлләр Сөләйман галәйһиссәлам чорында башкарылды. Белүебезчә, Сөләйман галәйһиссәламгә адәмнәр, хайваннар, кош-кортлар һәм хәтта җеннәр дә хезмәт итә иде.

Берникадәр вакыт узганнан соң, Сөләйман галәйһиссәлам вафат булгач, шәйтан аның тәхете астына сихер китабы салды. Һәм кешеләргә чыгып, Сөләйман сезнең белән нинди ысуллар кулланып идарә иткәнен беләсезме, дип барысының да күңеленә шик салды. Килеп карасалар, Сөләйман галәйһиссәламнең тәхете астында сихер китабына тап булдылар. Һәм пәйгамбәр галәйһиссәлам кулы астында булучы кайберәүләр, чыннан да, ул барлык мәхлукатлар белән сихер аша идарә иткән, дип нәтиҗә чыгардылар.

Аллаһы Тәгалә әлеге кыйсса турында «Әл-Бәкара» сүрәсенең түбәндәге аятендә бәян итә:

**«Яһүдләр, Сөләйман пәйгамбәрдән соң шәйтаннарның сихер белемен өйрәтүләренә дә иярделәр. (Шәйтаннар сихер китабын язып,Сөләйман галәйһиссәлам тәхете астына куйдылар. Сөләйман үлгәч, бер шәйтан кеше сурәтендә килеп: «Әгәр Сөләйман галәйһиссәлам калдырган мирасын белергә теләсәгез, тәхете астын карагыз», – диде. Чыннан да, тәхет астыннан бер китап табып алдылар, ул китапта сихер белеме язылган иде. Яһүдләрнең галимнәре: «Аллаһы сакласын, бу китапка иярә күрмәгез, бу китап Сөләйман китабы түгел, ләкин бу шәйтан эше», – диделәр. Әмма яһүдләрнең наданнары бу Сөләйман галәйһиссәламнән калган китап дип, сихерне кабул иттеләр). Сөләйман галәйһиссәлам кяфер булмады, ягъни ул сихер белән шөгыльләнмәде һәм сихер китабын язмады, әгәр бу эшләрне эшләгән булса, әлбәттә, кяфер булыр иде. Шәйтаннар кяфер булдылар, чөнки сихер китабын алар язды һәм кешеләргә өйрәттеләр. Бабил шәһәрендә Һарут вә Марут исемле ике фәрештәгә иңдерелгән сихерне дә шәйтаннар кешеләргә өйрәттеләр. Әмма бу ике фәрештә өйрәтмәделәр сихерне һичкемгә, яки өйрәтсәләр, әйттеләр: «Дөреслектә, без сезгә фетнәбез, Аллаһы безне җибәрде сихер белән сезне сынар өчен җибәрде, әгәр сихер белән шөгыльләнсәгез, кяфер булырсыз. Сихерне өйрәтеп һәм аның белән эш кылып, кяфер булмагыз» – дип. Фәкать кяфер булудан курыкмаган җеннәр, ир белән хатын арасын боза торган сихерне шул ике фәрештәдән өйрәнделәр. Ул сихерчеләр, сихерләре белән һичкемгә зарар итүче түгелләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә теләге белән генә зарар итәрләр. Яһүдләр дә зарар итә торган, һич файдасыз булган сихерне өйрәнделәр. Шиксез, алар белделәр: Тәүратта укып, сихер белән шөгыльләнгән кешегә Ахирәттә Аллаһыдан газабтан башка һичнәрсә юклыгын. Ул сихерчеләрнең үзләрен сихергә сатулары нинди яман сәүдә, ягъни җәннәтне биреп җәһәннәмне алдылар, әгәр белсәләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102.

Ягъни сихерче булыр өчен кяфер булырга кирәк. Мөселман кешесе сихерче була алмый. Аллаһы Тәгалә яһүдләр шәйтанның ялганына иярделәр, әмма Сөләйман сихерче булмады, ди.

Иблис мәлгунь, миңа җир йөзендә ярдәмчеләр кирәк, дип эзләп йөрде. Үзенең начар эшләрен тормышка ашыруда ярдәмчеләр итеп ул сихерчеләрне сайлады.

Аллаһы Тәгалә бу ике фәрештәнең исемен үзгәртеп аларны Һарут һәм Марут дип атады.

**– Белүебезчә, сихерчегә, күрәзәчегә йөрүчеләр, ниндидер сәбәп белән, аларның һәр сүзенә ышана, алар кушканнарны үти торган була. Шул рәвешле, аларның йогынтысына керә. Ә менә сихерчеләр үзләре кемнәргә дә булса буйсынамы?**

Сихерчеләр шәйтаннарга хезмәт итә. Мөселманнарның Аллаһы каршысында дәрәҗәләре булган кебек, сихерчеләрнең дә шәйтан каршында үз дәрәҗәләре бар. Алар күбрәк гөнаһ кылган саен начарлык дәрәҗәсендә югарырак күтәреләләр. Шул рәвешле, сихерче тулысынча шәйтанга бәйле була, аның һәр фәрманын башкара, көнен һәм төнен аңа хезмәт итә. Әммә аны тыңламаса, авырый башлый, чөнки барлык эшләгән сихерләренең золымы үзенә кайта. Әле бу иң яманы түгел . Иң начары: бу сихерчеләрнең җан бирер алдыннан кичергән газаплары.

Кайбер кеше сихерне адашу һәм харам гамәл генә дип уйлап, җиңел карап, сихергә кереп китә. Хәтта аның кяферлек, ширек икәненә җитди карамый. Әмма сихернең зарары, аның проблемалары шактый тирәндә. Чөнки, кеше мөнәсәбәтләрен бозып, низаг, фетнә чыгарып, акча эшләп йөрүче бу затлар җәмгыятькә әйтеп бетергесез зыян сала.

**– Сихерчегә баручы кешенең хөкеме нинди?**

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Кем дә кем бер сихерчегә, күрәзәчегә килеп, аның бер генә сүзенә булса да ышанса, аның кырык көн укыган намазы кабул булмас», – дигән хәдисе дә билгеле. Икенче бер хәдистә, шулай эшләгән очракта, адәм баласы Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән һәрбер нәрсәгә кяферлек китергән кебек була, ди. Гали бине Әбү Талиб, сихерче һәм күрәзәче икесе дә кяферләр, диде.

Әбү Муса Әл-Әшгарыйдан килгән Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисенә күз салыйк: «Өч төрле кеше җәннәткә кермәс: хәмер белән мәшгуль булган кеше, үз туганнары белән арасын бозган кеше, сихергә ышанган кеше».

**– Әйтегез әле, сихер, бозым, күз тиюгә дучар булган кеше үзендә нинди дә булса үзгәрешләр тоямы?**

- Кайвакытта кешеләрнең, авырып киттем, юктан гына хәлем китә, табиблар сәбәбен әйтә алмый, чөнки тикшеренүләр узгач, сәламәтлегем белән бар да тәртиптә икәнен ачыкладылар дигәнен ишетергә туры килә. Менә мондый очракларның күбесе шушы зәхмәт тию сәбәпле була да инде. Андый вакытта кеше үзен начар хис итсә дә, тыйб (медицина) ягыннан барлык күрсәткечләре дә яхшы була.

**– Сихер, бозым һәм күз тию арасында нинди аерма бар?**

- Ишеткәнегез бардыр, бу кешенең күзе «каты», аның күзе тиз тиючән, диючеләр бар. Чыннан да, кайбер кеше үзе дә сизмәстән һәм еш кына берниндидә начарлык теләмичә дә берәрсенә күз тидерергә мөмкин. Мондый хәлләр булмасын өчен кеше нәрсәгә дә булса сокланып караса, һәрвакыт «сөбеханәллаһ», «мә шә Аллаһ» сүзләрен әйтергә тиеш.

Ә менә сихер, бозым белән эшләр башкачарак тора. Сихер ясаучы яки аны кемдер аша ясатучы кеше бу гамәлен белә торып, махсус, икенче бер кешегә золым теләп ясый.

Тик шунысын истән чыгармасак иде: кешегә килгән зыян да, яхшылык

**• Әңгәмә рубрикасы •**

*Дәвамы. Башы 4нче биттә*



та бары Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы аша башкарыла. Чөнки Габдуллаһ бине Габбас Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисен риваять итте: «Әгәр дә җир йөзендәге барлык кеше дә җыелып сиңа файда китерергә теләсәләр, Аллаһы язганын гына кыла алырлар. Һәм әгәр дә барысы да җыелып сиңа зыян эшләргә теләсәләр, монда да Аллаһы язганыннан артыгын эшли алмаслар.

**- Шулай да бу золымлыкның корбаны булмас өчен кеше нәрсә эшләргә тиеш? Үзен бу бәлаләргә тарудан саклый аламы?**

- Алдагы җавапта без кешегә нәрсә дә булса Аллаһы Тәгаләнең әмере белән генә ирешә, дигән идек. Әлбәттә, сихердән сакланунын үз чаралары бар. Белүебезчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенә дә сихер ясаганнар иде һәм бу хәлдән соң аңа «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләре иңде. Шуларны укыганнан соң Аллаһының Илчесе бу зәхмәттән арынды. Әлбәттә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның яшәү рәвеше белән безнекен чагыштырып булмый. Ул һәрдаим Аллаһыга тәвәккәл кылган, Аның сүзеннән чыкмаган бөек кеше. Әмма без аның яшәү рәвешеннән үрнәк алып камиллеккә омтыла алабыз. Кеше сихер, күз тиюләрдән сакланыр өчен госел, тәһәратле йөрергә тиеш, иртәкичләрен, бигрәк тә йокларга ятар алдыннан «Аятел Көрси», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен укырга, хәрам ризыктан ерак булып, хәләл белән генә тукланырга һәм әлбәттә инде динебез Ислам кушканча, изге Китабыбызга һәм сөннәтебезгә туры килгәнчә яшәү рәвеше алып барып, әйләнә-тирәдәгеләргә миһербанлы, шәфкатьле булып яшәргә омтылырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә адәм балаларын сихерче, күрәзәче кебек затлардан ерак кылып, начар юлда булучыларны тугры юлга чыгарсын, аларның зарарлары тигәннәргә шифа һәм дәва бирсә иде.

■ **Әңгәмәне Ләйлә Әхәтова оештырды.**

# Нәрсә ул никах? Беренче никах кемнәргә укылган?



Никах «ант-вәгъдә» дигән сүз, ягъни никахлашучыдан «риза булып барасыңмы?» дип сорaганда, ул «шушы кеше белән гомерем буе никахыма тугры яшәргә ризамын»,— дип вәгъдә бирергә тиеш. Менә шуның белән дә никах иң саваплы гамәлгә керә. Бу вәгъдәбез белән без үзебезнең Адәм галәйһиссәлам нәселеннән булуыбызны, гакыллы зат икәнебезне, хайваннан аерылып торганыбызны күрсәтәбез. Никах ул — шатлык, сәгадәт туе.

Беренче никах кемнәргә укылган дигән соравыгызга җавап итеп, риваятьләргә карaганда, Адәм галәйһиссәлам белән Хәвва радыяллаһу ганһәгә, Аллаһы Тәгаләнең әмере илә, никахны Җәбраил фәрештә укыган.

# Аллаһы Тәгаләнең никах хөкемен иң беренче кем бозган?

Бу гамәлне кылучы иң беренче кеше – Адәм галәйһиссәламнең углы Кабил. Ул никах хөкемен бозып, Аллаһы Тәгаләгә дошман булды, үзенә хәрам булган Әкълимәгә өйләнер өчен кардәше Һабилне үтерде һәм кяфергә әйләнде. Шуннан соң Кабил ата-анасыннан, туганнарыннан аерылып китеп, һәлак булды. Хак Тәгаләгә каршы барып ул үзенә зарардан башка берни дә китермәде. Җир вә күкнең ләгънәтен алды һәм бу ләгънәттә мәңге калды. Күргәнебезчә, Раббыбызга каршы барып, Аның гадел хөкемнәренә хилафлык кылып, әүвәлдә һичкем уңышка ирешә алмаган, Аллаһыдан алачак мәңгелек нигъмәтләрдән, җәннәттәге дәрәҗә һәм чын бәхет-сәгадәттән мәхрүм калган. Бүгенге көндә дә, Хак Тәгаләнең әмеренә каршы барып, һичкем максатына ирешә алмас.

### Бүгенге яшьләр бер-берсенә юл куя белмичә аерылалар, аннары яңадан кушылганда никах яңартып тормыйлар. Кабаттан кушылганда алар никах яңартырга тиешләрме?

Ир белән хатын кайтарылмый торган талак, ягъни «гайр раҗига» белән аерылышкан булсалар һәм алар яңадан кушылырга уйласалар, бу вакытта ике яктан да шаһитлар чакырылып, яңадан никах укылырга тиеш. Әгәр дә инде кайтарыла торган талак — «раҗигъ» белән аерылышкан булсалар, алар никахларын шаһитлардан башка кабаттан яңарта алалар. Никахка бит әле кылган гөнаһлар, хаталану, ялгышулар да зарар китерә. Яшьләр уйлап-нитеп тормыйча, бер-берсенә төрле авыр сүзләр әйтәләр, ахырдан гына никах бозылмаганмы икән, дип шөбһәләнәләр. Шушы шикшөбһәләрне калдырмас өчен никах яңартсагыз дөрес булыр.

Әгәр дә инде үпкәләшүләр ул кадәр зурга китмәгән булса, ир белән хатын икесе дә: «Әллааһүммә инниәүҗәд-дидү имәәни үә никәәһи би-каули ләә иләәһә илләллааһү Мухәммәдүр-расүлуллаһ», ягъни «Ий Раббым Аллаһ, иманымны яңарттым!» дип әйтергә тиешләр.

# Никах гарәпчә генә укылырга тиешме?

Никах гарәп телендә һәм ана телендә дә укылырга мөмкин. Әмма шаһитларның бу сүзләрне аңлавы мәҗбүри. Никах укыганда мулла гаиләнең әһәмияте, ир белән хатынның хаклары, киләчәк буынны дөрес тәрбияләүнең әһәмияте турында вәгазь сөйләсә – бик яхшы булыр.

Әгәр кыз кияүгә чыгарга теләмәсә, беркем дә, хәтта әтисе дә аны бу эшкә мәҗбүр итәргә тиеш түгел. Әгәр дә кыз риза булса, никах мәҗлесендә кызның әтисе кияү кешегә: «Мин кызымны сиңа хатынлыкка бирәм»,— дип әйтә. Ә егет: «Мин аны хатыным итеп алдым»,— дип җавап бирә. Шуннан соң кыз һәм кияү: «Ләә иләәһә илләлаһү Мухәммәдүр-расүлуллаһ» дип иман кәлимәсен әйтәләр. Никах хөтбәсе вә дәхи Коръән аятьләре укыла һәм яшьләргә нык иман, бәхет, иминлек сорап дога кылына.

Егет белән кызның теләге булса, никах мәҗлесе кунакларны сыйлау белән тәмамлана. Кунаклар чакыру һәм аларны хәләл ризык белән кунак итү яхшы гамәл санала. Чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенең бер сәхабәсе өйләнгәндә: «Бер сарыкны корбан чалып булса да, кунакларыңны сыйла»,— дип әйткән.

# Никах ул фарызмы, әллә сөннәтме?



Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «Никах — минем сөннәтем. Минем сөннәтемнән баш тартучы минем өммәтемнән түгел». Ул Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итәм дип, никахтан баш тарткан зәһедләрне (аскетларны) бик каты тәнкыйтьләгән . Икенче бер хәдисендә: «Мин — сезнең арада иң тәкъвалысы. Ләкин мин ураза да тотам, ифтар да кылам, намаз да укыйм һәм йоклыйм да, хатын-кызларга да өйләнәм. Минем сөннәтемнән баш тартучы минем белән түгел»,— дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тормышта иң зур шатлык изге хатын икәнне ассызыклап болай дигән: «Безнең тормышыбыз — шатлык, ә анда иң зур шатлык — изге хатын».

■ **Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк**

# Гашурә көне



Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Мөхәррам ае – һиҗри календарь (тәкъвим) буенча беренче ай булып килә. Харам булган, сугыш кылу тыелган дүрт айның берсе булып санала (зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм раҗәб айлары). Бу айның фазыйләтен күрсәтеп, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең сөннәтендә искә алды. Шул сәбәпле, һәрбер мәселман бу айны лаеклы итеп үткәрергә тырышырга тиешле. Аллаһы Тәгаләне олылап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алып, салаватлар әйтеп үткәрсә, ин шә Аллаһ, зур әҗерләргә ирешер.

Бу айны кеше ничек итеп үткәрсә, аның калган бөтен айлары да шул рәвешле үтәр. Имам Газәли хәзрәтләре үзенең «Ихъя гулумуд-дин» («Иман турында фәннең яңадан торгызылуы») китабында болай дип искә алып үтә: «Әгәр берәү мөхәррам аен гыйбадәттә үткәрсә, һичшиксез аның хәер-бәрәкәте елның калган айларына да җитәр».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеннан соң ураза тотар өчен иң күркәм ай – ул мөхәррәм ае», – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү мөхәррам аеның бер көнен уразада үткәрсә, Аллаһы Тәгалә аңа утыз көн тоткан ураза әҗерен бирер», – дип хәбәр итә. Бу айның дәрәҗәсен күрсәткән башка бик күп хәдисләр һәм риваятьләр дә бар.

Бу ай ни өчен шул дәрәҗәгә күтәрелде соң? Ни өчен бу айга шундый игътибар кылырга кирәк? Моның төп сәбәбе булып бу айда булган кайбер мөһим вакыйгалар тора. Шуларның берсе – Гашурә көне. Мөхәррам аеның унынчы көнен «Гашурә көне» дип атап йөртәләр («ун» сүзе гәрәпчә – «гашәра»).

Алдан әйтелгәнчә, мөхәррам ае айларның иң өлкәне, ә аның 10 нчы көне –иң кыйммәтлесе булып санала.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, анда яшәүче яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотуларын күрә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сез бу көндә ни өчен ураза тотасыз?» – дип сорагач, алар бу көн – Муса галәйһиссәламнең Фиргавен гаскәреннән котылган көн икәнен, шул вакыйганы олылап тотуларын әйтәләр.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Нәхнү әхакку биһә – без ул көнне ураза тотарга хаклырак», – дип, ураза тота башлый. Ләкин яһүдиләрдән аермалы буларак, ул бу көннән алда тагын бер көн һәм соңыннан бер көн өсти (димәк, 9, 10, 11 нче көннәр).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Берәү Гашурә көнен олылап ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аның үткән елгы гөнаһларын кичерер», – дип хәбәр итә. Башка риваятьтә: «Әгәр кеше Гашурә көнендә бер кечкенә орлык кадәр генә булса да садака бирсә, Аллаһы Тәгалә аңа Өхед тавы кадәр әҗер бирер», – дип әйтелә. Шул рәвешле, мөселманнар бу көндә төрле изгелекләр кылалар, бер-берсен сөендерәләр, Аллаһы Тәгалә дә шул рәвешле аларны сөендерә.

Ни өчен соң бу көн мөселманнарның игътибарына лаек? Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бу көнне Аллаһы Тәгалә җир һәм күкләрне яратты, беренче кеше – Адәм галәйһиссәлам яратылды. Бу – аның җәннәткә кертелгән, аннан чыгарылган һәм дә тәүбәсе кабул ителгән көн.

Шулай ук бу көнне күп кенә пәйгамбәрләр төрле бәла-казалардан котылып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешкән. Мәсәлән:

– Нух галәйһиссәламнең көймәсе коры җиргә җитеп, Җуди тавы итәгенә туктаган;
– Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам туган;
– Гайсә галәйһиссәлам һәм Идрис галәйһиссәлам күккә ашкан;
– Ибраһим галәйһиссәламне дошманнары утка ыргытканнан соң, ул уттан котылган;
– Муса галәйһиссәлам Фиргавен гаскәреннән котылган;
– Юныс галәйһиссәлам зур балык (кит) карынынннан котылган;
– Әюб галәйһиссәлам авыруыннан дәваланган;
– Сөләйман галәйһиссәлам патша булган;
– Йосыф галәйһиссәлам зинданнан азат булган һ.б.

Димәк, бу көннең дәрәҗәсе, һичшиксез, зур. Гашурә көнендә түбәндәге догаларны укырга киңәш ителә:

**بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ**

**حَسْبُنَا اللهُ وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ**

**سُبْحَانَ اللهِ مِلْءَ الْمِيزَانِ وَمُنْتَهَى الْعِلْمِ وَمَبْلَغَ الرِّضَى وَزِنَةَ الْعَرْشِ لاَ مَلْجَاءَ وَلاَ مَنْجَأَ مِنَ اللهِ إِلاَ إِلَيْهِ سُبْحَانَ اللهِ عَدَدَ الشَّفْعِ وَالْوَتْرِ وَعَدَدَ كَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّاتِ كُلِّهَا، أَسْئَلُكَ (نَسْئَلُكَ) السَّلاَمَةَ بِرَحْمَتِكَ يآ اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ العَلِيِّ الْعَظِيمِ وَهُوَ حَسْبِى (حَسْبُنَا) وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ وَصَلَّى اللهُ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ خَيْرِ خَلْقِهِ وَعَلَى آلِهِ وَصَحْبِهِ أَجْمَعِينَ.**

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим**

**Хәсбүнәл-лаһи вә нигъмәл-вәкиил, нигъмәл-мәүләә вә нигъмән-нәсыйр.**

**Сүбхәәнәл-лаһи мил’әл-мизәәни вә мүнтәһәл-гыйлми вә мәбләгар рида вә зинәтәл-гарши ләә мәлҗә’ә вә ләә мәнҗә-ә минәл-лаһи иллә иләйһи.**

**Сүбхәәнәл-лаһи гадәдәш-шәфгый вәл-вәтри вә гадәдә кәлимәәтил-ләәһи әт-тәәммәәти күллиһә. Әс’әлүкә (нәс’әлүкә) әс-сәләәмәтә бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин. Вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә иллә бил-ләһил-галиййил-газыйм.**

**Вә һүә хәсби (хәсбүнәә) вә нигъмәл-вәкиилү вә нигъмәл-мәүләә вә нигъмән-нәсыйру.**

**Вә салләллааһү галә сәййидинә Мухәммәдин хайри халкыйһи вә галәә әәлиһи үә сахбиһи әҗмәгыйн**

Мәгънәсе: Бу дөньяда барча мәхлүкъларга да, Кыямәт көнендә мөэминнәргә генә рәхимле булган Аллаһы исеме белән. Безгә бары Аллаһы җитә. Иң яхшы ярдәмче, иң яхшы Мәүлә һәм яклаучылар арасыннан иң яхшы Зат. Аллаһыга Мизан тулганчы, Аның гыйлеме кадәр, Аның ризалыгын алганчы, Гареш авырлыгы кадәр мактаулар булсын. Аллаһыдан башка коткаручы юк. Аллаһыга так вә җөп саннар, Аллаһының камил сүзләре саны кадәр мактаулар булсын.

Синең рәхмәтең илә тынычлык сорыйбыз, ий Рәхимле вә Шәфкатьле.

Аллаһыда булган көч һәм куәт һичбер затта юк.

Ул миңа (безгә) җитә, Ул таянырлык иң яхшы Зат, ярдәм бирүче иң яхшы Зат. Иң күркәм кеше – Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның әһле бәйтенә вә сәхабәләренә Аллаһының салаваты вә сәламе булса иде.

Әс-Сухравәрди хәзрәтләре: «Гашурә көнне бу доганы 10 мәртәбә укырга хәленнән килгән кешенең янына ул елны Газраил фәрештә килмәс. Әгәр ул елны кешегә дөньядан китәргә тәкъдирендә булса, Аллаһы Тәгалә аңа бу доганы укырга мөмкинлек бирмәс!» – дигән.

Шулай ук тагын бер нәрсә хакында әйтмичә узып булмый, чөнки мәгълүмат чыганакларында бу вакыйганы киң яктырталар һәм аны Ислам дине белән бәйлиләр. Ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныгы Хөсәен вафат булган көн (626-680). Без ул көндә аларга дога кылабыз. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорыйбыз. Ләкин башка фиркаләр кебек шуннан артык гамәлләр кылмыйбыз.

**Дамир хәзрәт Гаффаров,**
**Лаеш мөхтәсибәте**

# Беренче мөселманнар шөгыльләнгән спорт төрләре

Ислам тәнне, рухны һәм зиһенне чыныктыра, ныгыта торган спорт төрләрен хуплый. Дөрес, кайбер искәрмәләр дә бар. Мәсәлән, спорт белән мавыгып китү кешенең башка эшчәнлегенә зыян салмаска тиеш. Элек мөселманнар түбәндәге спорт төрләре белән шөгыльләнгәннәр.

## Йөгерү

Йөгерү сәяхәт, сугыш һәм сәфәрләргә әзерләнүнең бер төре булган. Бер хәдистә килгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гайшә радыяллаһу ганһә белән ярышкан. Бер тапкыр ул Пәйгамбәребез галәйһиссәламне узган, икенчесендә исә өстенлек Пәйгамбәребездә була. Гарәпләр арасында үзенең тиз йөгерүе белән дан тоткан Хөзәйфә бине Бәдр исемле гарәп кешесе сәяхәтләр вакытында үз сәләтен күрсәтә торган булган. Бер төн эчендә ул, башкалар тугыз төн эчендә үтә торган араны йөгереп узуы белән аерылып торган.

## Атта йөрү һәм чабышу

Мөселманнар бик оста атта йөрү сәләтенә ия булганнар. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: **«Янә сезгә зиннәт өчен вә атлар өчен, йөкләр йөкләр өчен ат, качыр, ишәкләрне яратты һәм дә сез белмәгән нәрсәләрне халык кыла.»**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:8

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ат чабышларын үткәргәне билгеле. Махсус һөнәри ат чабышлары Мәдинәдән 6-7, ә һәвәскәр ат чабышларын сөюче кешеләр өчен бер миль ераклыгында оештырыла торган булган.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Әл-Әдба исемле дөясе булганы билгеле. Ул финишка беренчеләрдән булып килә торган булган, әмма бер юлы оттырган һәм мөселманнар да аның бу җиңелүен авыр кичергән. Бу күренешкә карата Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу Аллаһының кануны һәм Ул теләсә югарыга күтәргәнне түбәнгә дә төшерә ала», – дип җавап биргән.

## Уктан ату

Спортның бу төре мөселманнар арасында киң кулланылыш алган булган. Алар үзара төгәллектә ярышканнар, чөнки уктан ату дошманнарны тар-мар итүдәге мөһим коралларның берсе булып саналган. Уктан атуга мөселманнар балаларын кечкенәдән өйрәтә торган булганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Балаларыгызны уктан атуга һәм йөзүгә өйрәтегез», – дигән хәдисе билгеле.

## Фехтовать итү

Беренче мөселманнарда арасында бу спорт төрен «никаф» дип йөрткәннәр. Бу спорт төренең бер өлеше көрәшкә алып баручы махсус бер биюдән гыйбарәт булган. Хәдисләрнең берсендә нәкъ менә сөңгеләр белән бию, никаф искә алына.

## Көрәш

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам берничә ир-ат белән көрәшкән. Алар арасында Мәккәдә яшәүче, көрәш остасы Рөкәна бине Габд Йәзид бине Хәшим бине Габделмоталлиб та булган. Кешеләр ераклардан килеп аның белән көрәшә торган иде. Рөкәна Пәйгамбәребезгә: «Әгәр дә мине җиңсәң, мин Исламны кабул итәм», – дигән. Пәйгамбәребез көрәштә аны җиңеп чыккан һәм бу шулай өч мәртәбә кабатланган. Шуннан соң Рөкәна Ислам динен кабул иткән – шәһадәт кәлимәсен китергән. Пәйгамбәребез шулай ук Әбү Әл-Әсвад Әл-Җомахи исемле кеше белән көрәшкән. Ул шулхәтле көчле булган ки, хәтта ул берьюлы сыер тиресенә баскан һәм ун кеше ул тирене төрле яклатып үзләренә тарта башлаган. Ахыр чиктә алар аны тартып өзгәннәр, әмма Әл-Җомахиның аяк астыннан йолкып ала да, аны урыныннан кузгалта да алмаганнар.

## Авырлыклар күтәрү

Әлеге уенны уйлап чыгаручы, үзенең көче белән дан тоткан Җәбир бине Габдуллаһ Әл-Әнсари исемле кеше булган. Сәхабәләр арасында үзенең көче белән Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе аерылып торган. Ул Хәйбар сугышы вакытында үзенең калканын югалткан һәм аның урынына җиде кеше көче кирәк булган авыр ишек күтәреп сугышкан.

## Биеклеккә сикерү

Спортның бу төре «әл-кафиз» исеме белән билгеле булган. Бу уен төрендә катнашучылар сикерү өчен агач кисәге куллана торган булган. Уенның тәртипләре алдан сөйләшеп килешенгән.

## Таш ыргыту

Таш ыргыту гарәп әдәби китапларында да искә алына. Аны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныклары Хәсән һәм Хөсәен дә уйный торган булганнар. Тәртибе мондый: таш ыргытыр өчен чокыр казыла һәм катнашучылар анда таш ыргыта. Кемнең ташы чокырга төшә – шул җиңүче була.

## Йөзү

Гомәр бине Хәттаб радыяллаһу ганһу Шам җирләренә язган хатында: «Балаларыгызны уктан атырга, йөзәргә һәм шулай ук ат аркасына сикереп менәргә өйрәтегез», - дип юллаганы билгеле. Шулай ук: «Балаларыгызны йөзәргә өйрәтегез», - дигән хәдисе дә мәгълүм.

Сүз дә юк, динебез буенча, кешенең иң мөһим әгъзасы йөрәк дип саналса да, мөселман кешесе тәнен ныгыту, чыныктыру өстендә дә эшләргә тиеш. Физик яктан камилләшергә алынган вакытта өч шартны күз уңыннан җибәрмәскә кирәк: ул куркынычсызлык, файда һәм тыйнаклык.



■ islam-today.ru


# КОРБАН ГАЕТЕ – 2019: ФОТОМИЗГЕЛЛӘР

Август аенда бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм Гыйд әл-адха – Корбан бәйрәмен билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк өч көнлек бәйрәм чаралары узды. Башкалада төп бәйрәм тантанасы Галиев мәчетендә узды. Гает биредә иртәнге 3.30 сәгатьтә 11 яшьлек Коръән-хафиз Әхмәт Шаһмәмәдов башкаруында Коръән аятьләре укудан башланып китте.

Бәйрәм сөенечен бүлешү, бәйрәм вәгазен тыңлау һәм дин кардәшләр белән бер сафка басып гает намазын уку өчен тарихи мәчеткә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та килгән иде. Мөхтәрәм кунакны Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Бөек бәйрәм уңаеннан мөфти хәзрәт Рөстәм Нургали улына бәһасез истәлекле бүләк – ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан «Хозур» нәшрият йортында республика башлыгы өчен махсус тәүге нөсхә рәвешендә бастырылган Коръән мәгънәләренең татарчага тәрҗемәсен тапшырды.












# «Хозур» телеканалы файдалы тапшырулары белән куандыра

## Игътибар!

Якын арада «Хозур» телевизион каналында «Мәчетләр тарихы» һәм «Мөнәҗәтләр» дип исемләнгән яңа тапшырулар күрсәтелә башлаячак.

Инде эфирга чыккан «Намаз дәресләре» һәм «Әлифба сабаклары» дип аталган тапшыруларның да яңа чыгарылышлары көтелә. Игътибар итик, «Әлифба сабаклары» тапшыруының алып баручысы – «Тынычлык» мәчете имам-хатыйбы, Коръәнхафиз Тимур хәзрәт Камаев мөселман кардәшләребезне үтемле һәм аңлаешлы итеп гарәп хәрефләре белән таныштыра. Бу тапшыру бар яштәге кешеләр өчен – олыларга да, балаларга да файдалы булыр дип саныйбыз. Шулай ук «Намаз дәресләре» тапшыруы да намазга өйрәнүдә беренче адымнарын ясаучыларга файдалы һәм кирәкле дәресләр бирә.

Шунысы да куанычлы: хәзер «Хозур» каналын Ростелеком һәм Дом.ru кабель телевидениесе аша да карарга мөмкин.



«Әлифба сабаклары» тапшыруы

## Тапшырулар белән таныштыру

- **«Гаилә дәресләре».** Исламга нигезләнеп Рөстәм хәзрәт Хәйруллин белән гаилә мөнәсәбәтләрен төзергә өйрәнәбез.
- **«Бәрәкәтле гаилә».** Нияз хәзрәт Закиров һәм психолог Солтания Гатауллина белән берлектә гаилә проблемаларын чишәргә һәм ир белән хатын мөнәсәбәтләренең төрле этапларын җиңел үтәргә ярдәм итә торган тапшыру.
- **«Хәерле сәгатьтә».** Танылган шәхесләр белән әхлак, дин, тәрбия темаларына актуаль интервьюлар.
- **«Балам-багалмам».** Балалар ялын оештыру һәм тәрбия серләренә өйрәтә торган тапшыру.
- **«Тәмле булсын».** Танылган пешекче Резедә Хөсәенова белән кулинар мастер-класс.
- **«Рисалә».** Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы.
- **«1001 хәзинә».** Балаларга белем бирә торган тапшыру-уен.
- **«Җан авазы».** Мөслимәләр тормышындагы психологик проблемаларны хәл итүгә багышланган тапшыру.


"1001 хәзинә" тапшыруы

# Гошер садакасы



Галәмнәрне юктан бар итүче, безләргә Үзенең күп нигъмәтләрен биреп һәм безгә: «Әй, бәндәләрем, Миңа шөкер итегез – арттырып кайтарырмын», – дип мөрәҗәгать итүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә данмактауларыбыз, һәм шушы сынаулар белән тулы; ялгышу бик җиңел булган дөньяга пәйгамбәр итеп җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел төрләребездән чыккан салават һәм догаларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә бу дөньяга безне гыйбадәт кылыр өчен халык кылды. Раббыбыз иман китергән бәндәләре Аңа якынаю юлларын эзләп, тагын да якынайсын өчен, бөтенесен безгә җиңеллек белән кылган: кечкенә генә бер гамәл өчен дә Ул безгә зур-зур әҗерләрен бирә. Әйтик, Рамазан аенда ихластан ышанган һәм: «Аллаһы Тәгалә гафу итәр», – дип уйлаган ураза тотучының ничәшәр дистә еллар кылынган гөнаһларын да гафу итә. Без Аллаһы Тәгаләгә фәкать тырышлык куеп, һәрдаим гыйбадәтләребезне кылырга тиеш.

## Садака – изге гамәл

Гыйбадәтләр арасында күңелгә шатлык, бу дөньяда бәрәкәт һәм кешеләргә сөенеч китерә торган бер гыйбадәт бар: ул да булса – садака, ягъни үз малыңның бер өлешен мескеннәргә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә бирү. Мохтаҗ кешеләргә ярдәм иткәч, алардан килә торган рәхмәтләкне һәрберебезнең күргәне яки, һич-югы, ишеткәне бардыр. Моны аңлатып кына бетереп булмый. Әле ул яшерен рәвештә бирелсә, гомумән, күңелләр яктыра, чөнки садака алган кешеләр синең өчен ихлас күңелдән дога кыла. Ә андый кешеләрнең догалары кабул була. Шуңа әлеге төр гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә яшерен, ихластан эшләргә куша һәм савапның иксез-чиксез икәнен искәртә. Аллаһы Тәгалә Үзенең мөбарәк китабында безгә болай дип хәбәр итә:

**«Аллаһы юлында көндезләрен вә төннәрен ачыктан-ачык һәм яшерен малларын корбан итүчеләргә олы әҗерләр әзерләнгән. Һәм алар Ахирәттә курку һәм моңсулану һич белмәсләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Ягъни үз кулы белән эшләп алган малны Аллаһы Тәгалә кушкан җирләргә бирүчеләрне Аллаһы Раббыбыз Үзе зурлый.

Әбү Давыд хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Әгәр бер мөселман киемсез калган бер мөселманны киендерсә, Аллаһы Тәгалә аны җәннәт киеменнән киендерер. Әгәр ач калган кардәшен ашатса, аны да Аллаһы Тәгалә җәннәт ризыкларыннан ашатыр. Сусаган кардәшенә су биреп эчерсә, Аллаһы Тәгалә аны да җәннәт суы белән эчерер».

## Гошер садакасының әҗере

Шушы ризыкка бәйле садакалар арасында барыбызга да билгеле булган гошер садакасы бар. Бу төр садака иң хәерле һәм бәрәкәтле садакалар төреннән санала. Ә бу садаканы ничек итеп бирергә соң? Кем нинди күләмдә бирергә тиеш һәм ул кемнәргә бирелергә тиеш?

Бу садака акчалата бирелми. Ул яшелчә, җиләк-җимеш белән бирелә. Әгәр алар яңгыр суы белән үстерелгән булсалар, 10 нан бер өлеш, ә инде кеше үзе су сибеп үстергән очракта, 20 дән бер өлеш бирелә. Кайбер кешеләрдә түбәндәге ялгыш фикер дә йөри: имеш, бәрәңгедән 10 нан 1 өлеш, ә бүтән яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән 20 дән бер өлеш кенә бирелә. Әмма бу фикер – ялгыш. Яңгыр суы белән үскән барлык үсемлек: җиләк-җимеш, яшелчә һ.б. ризыклардан садака итеп 10 нан 1 өлеш бирергә кирәк.

Әмма бер күңелсез хәл дә бар: бүгенге көндә күп кеше шушы гыйбадәттән (изге гамәлдән) баш тарталар. Үзләренә аргумент итеп: «Мин үзем тир түгеп үстергән малымны кемгәдер илтеп бириммени? Бөтен кешегә өләшсәм, миңа нәрсә калыр? Миңа бирәүнең дә китереп биргәне юк бит әле», – дигән фикерләр китерәләр. Әлбәттә, бу халыкның гыйлемсезлеге аркасында һәм Аллаһы Тәгаләгә тиешле рәвештә тәвәккәл кылмаганлыктан килеп чыга. Без бит бакчага әйбер утыртканда уңышның бик күп булуын телибез. Ә үзебез шөкер итү йөзеннән әз генә булса да малны корбан итмибез, ягъни өлеш чыгармыйбыз. Әгәр дә шулай уйлым икән, җәмәгать, мин нинди күңел белән шул уңышны өмет итәргә тиеш инде. Шунлыктан, сүзләрне әйткәндә, нинди дә булса карар кылганда, уйлап эш итәргә кирәк.

## Садака ияләре

Садакаларны кемнәргә бирергә кирәк соң? Гадәттә, безнең җирлектә бу хәерне мохтаҗ кешеләргә, мәдрәсәләргә, мәчетләргә тапшыралар. Чыннан да, бу садаканы фәкыйрь, мескен, ятим кешеләргә, гыйлем алу юлындагы шәкертләргә, ялгыз яшәүче әби-бабайларга бирергә мөмкин. Бу акчалата бирелгән садакадан да шул ягы белән аерылып тора: авыр хәлдәге гаиләләргә акчалата садака биргәндә, алар аны дөрес юлларга кулланмаска да мөмкиннәр. Ә ризык белән биргәндә, мондый проблема булмаячак. Мин үзем, шәхсән, дөньяви уку йортларында укучы һәм тулай торакларда яшәүче мөселман егет-кызларга тапшыргалыйм. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака малны киметми», – дип әйткән, шулай булгач, кадерле җәмәгать, садакаларыбызны тапшырыйк. Бер капчык уңышыбызны садака итеп тапшырудан беркем дә ач яки ярлы булып калмаячак, Аллаһыга шөкер, без бүгенге көндә туклык заманында яшибез. Әгәр җиләк-җимештән үзебез өчен төрле кайнатмалар ясыйбыз икән, аннан да гошерне бирү тиешле була.

Ислам динендәге һәр бәйрәм, һәр садака, һәр гыйбадәт кешеләр арасын якыйнайтыр, сөендерер өчен боерылган. Әй, кардәшләрем, бер өммәт булып, бер-беребезгә ярдәм итешеп яшик. Кардәшенә ярдәм иткән кешегә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Шуңа күрә, әгәр дә без мохтаҗларга ярдәм итсәк, Аллаһы Тәгалә дә безгә ярдәм итәр. Аллаһы Тәгалә һәрбарчаларыбызга ике дөньяның да бәхетен насыйп кылсын.



■ **Алмаз Галимҗанов, Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе**

# Яңа ел – нәтиҗәләр ясау вакыты

Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, 31 август көнне без яңа 1441 һиҗри елга аяк басачакбыз. Ул без, мөселманнар өчен аерым мәгънәгә, игътибарга лаек Мөхәррам ае белән башланып китә. Мөхәррам аеның 10 нчы көне – «Гашурә» дип атала. Үз вакытында Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе нәкъ менә Мөхәррам аен һиҗри календарьның беренче ае итеп билгеләде. Мөселманнар яңа елны бәйрәм кебек билгеләп үтмәсәләр дә (Пәйгамбәребез ике бәйрәм – Ураза һәм Корбан гаете белән килде), аны яңа фазага аяк басу кебек кабул итәләр. Яңа елда бер елга үтәләсе яңа планнар корыла, яңа өметләр баглана.

Мөхәррам ае зөлхиҗҗә аеннан соң килгәнгә күрә дә, Гомәр Әл-Хаттаб бу айны беренче ай итеп куйгандыр. Моның да үз сәбәбе бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, бозыклыклар кылмыйча бу Йортка (Кәгъбәгә) хаҗ кылса, ул өенә анадан туган сабый кебек (пакь, гөнаһларсыз) кайтыр», – дип әйтә. Хаҗ кылганнан соң кеше үзенең гөнаһларының авырлыгыннан котылып кайтыр, шуңа күрә аны сабый бала белән чагыштырып булыр иде. Һәм әле генә хаҗ кылып, гөнаһларыннан арынып кайткан кеше, яңа елга чиста килеш аяк баса. Бу халәт кешегә алдагы елга оптимизм һәм уңай караш белән карарга мөмкинлек бирә, шулай ук элеккеге хаталарга һәм гөнаһларга әйләнеп кайтмыйча, елны тулысы белән шушы рухи чисталыкта үткәрергә этәргеч була.

## Мөхәррам аеның өстенлеге

Мөхәррам аеның беренче ай булуы гына аны зур дәрәҗәләргә күтәреп калмый. Беренчедән, бу айда олы кичә – «Гашурә» көне бар, икенчедән, бу ай һәр көнендә ураза тоту бик фазыйләтле булуы белән аерылып тора. Мөхәммәд Мостафа саллэллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеннан соң иң фазыйләтле ураза – Аллаһы аенда, мөхәррамда», – дип әйткән. Тагын бер хәдисендә: «Айларның саны унике, шул айларның дүртесе харам айлар булып санала, (аларның) өчесе чиратлашып киләләр: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам, ә дүртенче ай – раҗәб – җөмәдәл-ахыр һәм шәгъбан арасында», – дип әйтелә.

Кешеләр бу айда бер-берсен сүз беләндә, гамәле беләндә рәнҗетмәскә тиеш. Әйе, мөселманнар, гомумән алганда да, бер-берсен теле белән дә, гамәле белән дә, хәтта ки уйфикерләре белән дә рәнҗетмәскә тиешләр. Пәйгамбәребез мөэминмөселманның бер сыйфаты – башка кешеләрнең мөэминнең теленнән дә, кулыннан да имин булулары дип әйтте. Рәнҗетү бик зур гөнаһ санала. Киресенчә, Аллаһыдан сабырлык сорыйк.

## Яңа елга нинди планнар корырга?

Тиздән без 1441 елга аяк басабыз. Ә яңа елда һәрчак яңа үрләр көтә. Галимнәребез, гадәттә, үзләренең барлык кылган гамәлләрен дәфтәр яки блокнотка язып бара торган булганнар. Берәр ай тәмамлану белән, икенче айга керер алдыннан, үзләренең нинди изге гамәл, нинди начар гамәл кылганнарын карап, анализлап чыга торган булганнар. Аннан соң икенче айда начар гамәлләрен төзәтү, изге гамәлләрен арттыру өстендә эшли башлаганнар. Нинди изге гамәлләргә план корып була соң? Мәсәлән:

– ел дәвамында Коръән Кәримнең «Бәкара»сүрәсен ятлау;

– көн саен Коръәннән бер аять укый башлау;

– хаҗ кылырга дип акрынлап акча җыя башлау;

– биш вакыт намаз укый башлау һ.б.



## Мөселманнарда яңа елның һиҗри вакыйгасы белән бәйле булуының сәбәпләре

Мөселманнарда яңа ел нинди чара белән бәйле соң? Гарәпләрдә бу айлар күптәннән билгеле булалар. Югарыдагы Коръән аяте шуны дәлилли. Әмма Пәйгамбәребез вафатыннан соң берничә вакыт үткәч, дөресрәге Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе хәлифә булган вакытта айларны ел белән бергә язарга кирәк дигән фикер туа. Бу мәсьәлә дәүләтнең төрле төбәкләреннән килгән хатлар аркасында ачыла. Ул хатларда ай исеме язылган була, әмма елы билгеләнми. Шул сәбәпле, мөселманнарның әмире олы сәхабәләрдән торган шура җыеп, бу мәсьәләне күтәрә. Кемнәрдер мөселманнарның елына башлангыч итеп Пәйгамбәребез туган датаны алырга тәкъдим иттеләр, кемнәрдер Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек иңгән елны алырга куштылар. Әмма беренчесендә Ислам турында беркем дә белми иде, ә икенчесендә исә Ислам дине бик көчсез вакыт иде. Әлбәттә, ел исәбен Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафатыннан башларга да тәкъдим ителде, әмма Ислам календарен кайгылы елдан башлыйсылары килмәде.

Әмма ахыр чиктә ел башы итеп һиҗрәт вакыйгасы алына, ягъни миладиел белән караганда бу 622 елны була. Пәйгамбәребез Мәккәдәге әзәрлекләүләр ешайгач, Мәдинә (ул вакытта әле ул Йәсриб була) шәһәренә күченергә карар кыла. Мөхәммәд галәйһиссәлам шулвакыттагы мөселманнар белән Мәдинәгә күченгәч, Ислам дине куәтләнә, бер шәһәрдә бик күп мөселманнар бергә яши башлый. Ул вакытта Мәдинә халкы Мәккәдән килгән мөһаҗирләрне иң күркәм каршылау белән каршы алалар, аларга үзләренең йортларын, малларын бүләк итәләр. Һәм бу шәһәрдә мөселманнар үзләренә иминлек табалар. Һиҗрәтне шуңа да Ислам диненең чәчәк аткан, ныгыган чагы да дип йөртәләр. Ул мөселманнар дөньясында гына түгел, бөтен кешелек дөньясында да мөһим борылыш чоры дип карала. Шулвакыттан Ислам дөньясы мәдәнияте, гыйлеме, фәне югарыга таба күтәрелә башлый. Ислам дине галимнәре уйлап чыгарган бик күп җиһазлар, тыйб (медицина), оптика приборлары; алар нигез салган төгәл фәннәр – математика, мәсәлән – бөтен дөньяга тарала, өйрәнелә.

Ни өчен бүгенге мөселманнар григориан календаре белән генә файдаланмыйлар дигән сорау туарга мөмкин. Югарыда әйтеп узганыбызча, бу айлар гарәпләрдә бик күптәннән билгеле була. Шулай ук вакытны айга карап билгеләү бар кеше өчен дә җиңел булган. Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Көндез кояшны, кич айны нурлы-якты кылучы зат та Аллаһы Тәгаләдер, елларны вә башка хисапларны белер өчен ул айга урыннар билгеләде.**

«Юныс», 109:5

Ягъни Аллаһы Тәгалә Үзе үк күк җисемнәре ярдәмендә вакытны билгеләргә куша. Без, мөселманнар, бер ай дип күктәге айның циклын әйтәбез. Һәм бу дөреслеккә күбрәк тә туры килә. Шуңа да карамастан, миладибуенча да 30 яки 31 көнне дә бер ай дип әйтергә күнеккән инде без. Ни өчен бүген дә кулланабыз соң? Ислам динендә бик күп әһәмиятле вакыйгалар булган. Һәм аларның барысы да тарихка һиҗри айлардагы даталар белән кереп калган (Рамазан, Бәраәт, Гарәфә, Гашурә һәм башкалар).


## Гашурә көне уразасы

Аллаһының Илчесе бу көнне ураза өчен аерым билгели торган булган. Гашурәдән кала Пәйгамбәребез тарафыннан төгәл датасына кадәр билгеләнә торган бүтән бер көн дә булмаган. Бу көн турында Ибне Габбастан сорагач, ул: «Пәйгамбәребезнең бер көннең икенчесенә караганда бөегрәк булганы аркасында, шулай ук бер айның икенче айга караганда бөегрәк булганлыгы аркасында ураза тотканын хәтерләмим. Бары тик бер ай һәм бер көннең бөеклеге аркасында ураза тота иде, ул – мөхәррам. Әмма Рамазан моңа карамый», – дип җавап биргән.

Әгәр дә кеше бу уразаны хак курку белән куркып, ярлыкауга өмет белән башкарып чыга алса, аның узган ел өчен булган гөнаһлары ярлыканачак. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнән Гашурә уразасы турында сорагач, ул: «Ул узган елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип әйткән. Шуңа күрә шушы яңа елларны матур гына каршы алып, күркәм планнар корып, тагын бер елны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга тырышып яшәргә насыйп әйләсен.

■ **Сәхифәне Гәбделхәким Фәсхиев әзерләде**

# Финляндия халкына фин телендәге беренче Коръәнне бүләк иткән татар кешесе



Әхсән Бүренең Терийоки (хәзерге Зеленогорск) шәһәрендәге зиннәтле йорты.



1930 нчы елларда Әхсән Бүренең Тампер шәһәрендәге кибете.

Финляндия татарларының иң данлыклы кешеләре арасында Әхсән Бүре (20.03.1886-09.11.1945) исемле шәхес билгеле. Әлеге һәм аннан читтәге җирләрдә ул шулай танылса да, чынлыкта әлеге шәхеснең исеме – Зиннәтулла Имаметдинов.

Финляндия татары булган Зиннәтулла Имаметдинов чыгышы белән Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрьск районының Актүк (Актуково) авылыннан. Кечкенәдән бик сәләтле булып үскән Зиннәтулла яшьли сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый. Баштан Петербург, соңрак Финляндиянең (ул вакытта Терийоки дип аталган) Тампер шәһәрендә төпләнә. Биредә ул тукымалар һәм мех эшләнмәләре сатып байый.

Гаиләсенә күз салсак, Зиннәтулла, тугыз балалы гаиләдә тәрбияләнеп үсә. Әтисе Имадетдин Әхсән (1849-1906), әтисе Мәрхәбә Ибраһимова (1855-1941). Гаиләдә биш ир бала: Фәтхетдин, Заһидулла, Зиннәтулла , Габдулла, Габделкаюм, Габделхак һәм өч кыз бала: Хәлимә, Хәлизә, Катия тәрбияләнеп үсә.

«Әхсән Бүре» исеменең килеп чыгышы да кызыклы. «Әхсен» яки «Әхсән» исеме аңа гаиләсеннән бирелгән. XIX гасырда Рәсәй империясендә, ул вакыттагы тәртипләр буенча, балаларга фамилияне әтисе исеме белән бирәләр иде. Шуның өчен Зиннәтулла әтисе ягыннан Имаметдин фамилиясен ала. Соңрак үз исемен Әхсән дип атап, фамилиясе урынына «Бүре» тәхәллүсен куша.


Алдан ук билгеләп үткәнчә, Әхсән бик зирәк һәм сәләтле бала була. Ул бик яшьли сәүдә эшләрендә катнаша башлый. Һәм бу тырышлыклары Әхсәнгә кирәкле тәҗрибә тупларга һәм җитди тормыш юлына әзерләнергә ярдәм итә. XIX нчы гасыр ахыры XX нче гасыр башында Түбән Новгород татарларының күпчелеге Петербург шәһәрендә эшләр алып бара торган була. Һәм 1907 нче елда әле яшь кенә булган Әхсәнне әти-әниләре Петербургка туганнарына озата. Соңрак алар өлкән абыйсы Фәтхетдин һәм тагын бер татар гаиләсе белән аерым фатирга кереп яши башлыйлар. Әхсән Бүренең эшләре бик нык алга китә һәм бу уңайдан ул Финляндиянең ул вакытта Терийоки (Лениногорск өлкәсенең хәзерге Зеленогорск шәһәре) дип аталган шәһәрендә сәүдә эшләре белән шөгыльләнә башлый. Билгеләп үтик: ул вакытта Финляндия Рәсәй империясенә кергән һәм аның чикләре Петербургка якын булган.

1910 елда Әхсән Бүре үзенең бөтен эшен Терийоки шәһәренә күчерә. Аның сәүдәсе һәм милке елдан-ел арта бара. Алга киткән эшләрендә ярдәм итәр өчен ике кече энесен Гәбделхакны (1891-1944) һәм Габдулланы (1888-1949) үзе янына чакырта. 1917 елга абыйлы-энеле туганнар шактый керем туплыйлар. 1919 елда, Финляндия бәйсезлек алганнан соң, Әхсән Бүре үзенең эшчәнлегенең бер өлешен Финляндия көнбатышында урнашкан, тагын да эрерәк – Тампер шәһәренә күчерә. 1922 елда анда мех эшләнмәләре, тукымалар һәм төрек товарлары өчен зур кибет ача.

Әхсән Бүре дини гыйлемгә дә ия булган. 1916 елда ул дин өлкәсендәге имтиханнарны биреп, имам вазыйфаларын башкаруны үз өстенә ала. Алга таба аның бу сыйфаты финлыларны Ислам дине белән таныштыруга этәрәчәк тә. Киләчәктә Әхсән Бүре Финляндия татарлары арасындагы дөньяви һәм рухи лидерларның берсенә әйләнә. Ул актив рәвештә Рәсәй һәм Төркиянең дин эшлеклеләре белән аралаша. Советлар союзы үзенең чикләрен япканнан соң, ул Төркия белән элемтәләрен тагын да ныгыта. Әхсән Бүре хәйриячелек өчен акча кызганмый. 1930 нчы елда Тампер шәһәрендә фин-төрек мәктәбен ача. Шулай да әлеге шәхеснең финлылар өчен күрсәткән иң төп хезмәте ул – Финляндия халкын Коръәни-Кәрим һәм аның тәфсире белән таныштыру. Әлеге җиңел булмаган бурыч бик күп тырышлык һәм чыгымнар таләп итә. Әхсән Бүренең хисабына һәм аның ярдәме белән Коръән фин теленә тәфсир кылына һәм 1942 елда Тампер шәһәрендә бастырып чыгарыла. (Бу эш инде 1936 елда ук тормышка ашырылырга планлаштырылган булган.).



Фотода Әхсән Бүре



Коръәнне тәфсир кылу һәм изге китапны бастыру Финляндия татарлары өчен зур казаныш һәм истәлекле, тарихи вакыйга була. Әхсән Бүре бу гамәле белән үз исемен Финляндия тарихында мәңгеләштерә. Әлеге вакыйгалардан соң эшмәкәр илнең бик күп танылган шәхесләреннән рәхмәт хатлары ала. Бигрәк тә рәхмәт сүзләрен Әхсән Бүре Финляндиянең элеккеге президентлары К. Дж. Штольберг һәм П. Е. Свинхуфвуд, чит ил эшләре министры Штольберг һәм П. Е. Свинхуфвуд, Югары суд рәисе Аарне Рекола, Хельсинки университеты ректоры, математик Рольф Неванлинна һәм башка бик күп күренекле шәхесләр тарафыннан кабул итә.




Хельсинкида мөселман (татар) зиратында Әхсән Бүре һәм хатының каберләре.

■ Islam-today.ru сайтыннан

# Яңгыр белән курку тойгысы арасында нинди бәйлелек бар?



Яңгыр ни рәвешле кешене тынычландырырга, ныгытырга сәләтле? Алар арасында нинди бәйлелек бар? Моны аңлар өчен Коръәндә килгән гаҗәеп аятькә күз салыйк:

**Сугыш сәфәрегездә Аллаһы Үз рәхмәтеннән сезгә йокы салды, тынычланып йоклап куәт алдыгыз вә сезгә күктән яңгыр яудырып пакьләнүегез өчен, юынып рәхәтләндегез вә ул яңгыр белән күңелегездән шайтан вәсвәсәсен китәрер өчен, чөнки шайтан: "Үзегез Аллаһының сөекле бәндәсебез дип әйтәсез, хәлбуки үзегез сулы урында да була алмадыгыз", – дип вәсвәсә кылган иде. Яңгыр яугач мөселманнар суга туендылар да, шайтанның вәсвәсәсе юк булды. Дәхи ул яңгыр белән үзенең сезгә ярдәм бирәчәгенә ышануыгызны күңелләрегездә мәхкәм кылыр өчен, вә яңгыр белән аякларыгызны комлы җиргә куәтле кылыр өчен. Чөнки комлы җир, яңгыр яуса, такталаныпката».**

«Әнфәл / Табыш», 8:11

## Тәфсир күзлегеннән караганда

Әлеге аятьне тәфсир кылып Ибне Кәсир болай диде: «Әл-Гауф бине Габбасның сүзләренә таянып Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен китерә: «Мөшрикләр үзләренең кәрваннарына ярдәм итәргә, аны сакларга теләп, Бәдер ягына чыктылар. Һәм мөселманнардан алда килеп, сулыкларны камап алдылар. Нәтиҗәдә, мөселманнар су эчәргә интегеп бик авыр хәлдә калды, хәтта намазларын да тәһарәтсез укырга мәҗбүр булды. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә күктән елгалар булып ага торган яңгыр индерде. Шул сәбәпле мөселманнар сусаулары басылганчы су эчеп, савытларын да тутырды, хайваннарын да эчерде һәм тәһарәт тә алдылар.».

Аллаһы болай эшләп аларны чистартты һәм табан асларын ныгытты. Моның сәбәбе: Аллаh Тәгалә яңгыр җибәреп, мөселманнар һәм мөшрикләр арасында булган комлы җирләрне катырды һәм алар тыгыз җиргә басып йөри алдылар.

## Тыйб (медицина) ягыннан фикер йөрткәндә

Табиблар, курыкканда, кеше организмында аның әгъзаларын калтырата торган махсус матдәләр бүленеп чыга, диләр. Кешенең хәләтен җиңеләйтер, калтыравын киметер өчен аңа су бөркергә кирәк. Нәкъ шулай ук Аллаһы тарафыннан җибәрелгән яңгыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләренең табан асларын ныгыта. Бу, яңгыр тигәч, комның кисәкләре тыгызланып, аларга басырга мөмкин булу белән бәйле.

■ **islam-today**

# Исламда әйләнә-тирәдәгеләргә игелекле булуның мөһимлеге

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә игелекле булу, күркәм гамәлләр кылуга бик зур урын бирә.

**«Иман китереп, изге гамәлләр кылган хак мөэминнәр җәннәт әһелләре, алар анда мәңге калырлар.»**, - дип әйтелгән изге китапта.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:82

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик мәрхәмәтле, шәфкатьле кеше булган . Аның тормышында булган бер кыйссаны искә төшереп үтик.

Белүебезчә, пәйгамбәребез ачыктан-ачык рәвештә Исламны тарата башлагач, аңа каршы чыгучылар да, аның турында начар сүзләр сөйләп йөрүчеләр дә бик күп булган. Ул кешеләр пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында берни белмәсәләр дә, хәтта аның белән аралашканнары булмаса да, Расүлебезгә каршы барганнар. Шундыйларның берсе – олы яшьтәге авыру һәм сукыр бер яһүди кешесе базарда җирдә утырган хәлендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яманлап сөйли торган булган. Ә Пәйгамбәребез һәр көнне килеп, үз куллары белән шул кешене ашатып-эчерткән, әмма аңа үзенең Аллаһының Илчесе икәнен белгертмәгән. Билгеле инде, әлеге сукыр кеше үзен тукландыручы мәрхәмәтле затның кемлеген белмәгән, танымаган. Шулай көн арты көннәр узган, бу күренеш һәркөнне кабатланган. Әмма бер көнне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм фани дөньяны калдырып бакыйлыкка күчкән.

Белүебезчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тугры сәхабәләре аның һәр гамәлен үзләренең дә тормыш рәвешенә кертә торган булганнар. Пәйгамбәребез вафатыннан соң Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе анабыз Гайшә радыяллаһу ганһә янына килеп: «Йә, Гайшә, Аллаһының Илчесенең без белмәгән тагын нинди гамәле калды?» – дип сораган. Гайшә анабыз Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең карт яһүди янына йөрүен сөйләп биргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бу вазифаны үз өстенә алып, Пәйгамбәребез кебек, яһүдине ашатырга, дип базарга килгән. Сукыр яһүди сәхабәнең кулыннан ризык алуга ук: «Син минем яныма килеп йөрүче кеше түгелсең, аның куллары башка төрле иде. Элегрәк яныма йөргән игелекле кеше кайда?» – дип, сораган. Бу сүзләрдән соң Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе елап җибәргән һәм яһүдигә мона кадәр аның янына пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе килеп йөргәнен әйткән. Бу яһүди кешесе сәхабәнең әйткәннәренә гаҗәп калып, үзенең кайчандыр Пәйгамбәребезне яманлаганына бик оялган һәм елап, нинди чиста һәм дөрес сезнең динегез, дип Исламны кабул иткән.

Динебез тарихында мондый һәм аңа охшаш кыйссалар гаять күп. Пәйгамбәребез үзенең ачык мисалында әйләнә-тирәдәгеләргә мәрхәмәтле, миһербанлы булуның мөһимлеген күрсәткән. Ихлас, игелекле, олы җанлы, гадел, күркәм холыклы Пәйгамбәребез үз-үзен тотышы белән кешеләрнең хөрмәтен казанган, ятауларына лаек булган.

Коръәндә Пәйгамбәребезнең бу сыйфаты хакында аять бар:

**«Ий Мөхәммәд! Аллаһының рәхмәте белән өммәтеңә шәфкатьле булдың, әгәр каты күңелле булсаң, әлбәттә, синең тирәңнән качар иделәр.»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Шуңа күрә, Пәйгамбәребез вафатына күп гасырлар үткәч тә, аның кешелек тарихында зур урын алып торуы, мөселманнарның башлыгы, алар өчен үрнәк кеше булуы гаҗәп түгел. Чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үз мисалында дөрес яшәү рәвешенең нинди булырга тиешлеген күрсәткән шәхес.

■ *Лилия Җиһан*

# Аллаһының могҗизасы булган хайван

Дөя – фикерләүчеләр өчен, Аллаһының бер билгесе, могҗизасы. Аллаһы Коръәндә кешеләрне дөнья яратылышының, төзеклегенең, гармониясенең үзенчәлекләренә игътибар иттерер өчен, җир шарының киңлеге, күкләрнең биеклеге, тауларның бөеклеге турында сөйли. Дөрес, адәм баласы моны һәрдаим күреп торырга ияләшкән, әмма кеше фикерли белергә, нәтиҗәләр чыгарырга тиеш.

Шундый бер могҗизаларның берсе булган, гарәп чүлләрендәге мәһабәт, күркәм дөяләр турында фикерлик әле.

**«Әйә, кешеләр дөяләргә карамыйлармы, ничек халык кылынганнар-яратылганнар? Вә күккә карамыйлармы – ничек күтәрелгән? Вә тауларга карамыйлармы – ничек беркетелгән ул таулар? Вә җиргә карамыйлармы – ничек палас кеби түшәлгән?»**

«Гашийә / Каплаучы», 88:17-20

Дөяләрне моннан 4 мең еллар элек кулга ияләштерделәр һәм алар шул чорлардан бирле кешеләргә тугры йорт хайваннары булып хезмәт итә. Элеккеге вакытта, автомобильләр һәм башка транспорт чаралары булмаганда, гарәпләр әлеге җан ияләрен куллана торган иде, чөнки алар күп сыйфатлары белән чүллекләрдә йөрер һәм хезмәт итәр өчен иң яхшы хайваннар булып тора. Һәм хәтта хәзер дә күп кенә гарәп һәм төньяк Африка бәдәвиләре транспорт чаралары итеп дөяләрне куллануны кулайрак күрә.

Дөяләр бик чыдам һәм түземле җан ияләре. Алар башка хайваннар ике көннән дә ары яши алмаслык җирлекләрдә дә көчле булып кала.

## Дөяләрнең үзенчәлеге нидә?

Дөяләр куе йон белән капланган. Мондый барлыкка китерелеш әлеге хайваннарны кояш нурларыннан саклый. Сүз уңаеннан, дөя йоны бик кыйммәт йөри – аннан тукымалар, келәмнәр һәм башка әйберләр ясарга мөмкин.


Дөяләрнең күз күреме яхшы. Алар чакрымнан да ерак җирләрне күрергә сәләтле. Ә хәтерләре яхшы булу чүл җирлекләрендә җайлашырга, адашмаска ярдәм итә.

Гарәп җирлекләрендәге дөяләрнең аркаларында бер, урта Азия якларында яшәүчеләрендә ике өркәч була. Бу өркәчтә урнашкан май катламнары аларга берәр айга хәтле ризыксыз яшәү мөмкинлеген бирә.

Дөяләр бик көйле хайваннар. Алар берәр атна сусыз яшәргә мөмкиннәр, чөнки эчкән сулары эчләрендәге махсус капчыкта саклана. Сүз уңаеннан, дөяләр бик күп су эчә: бер утыруда ике йөз литр чамасы су эчәргә мөмкиннәр. Моннан тыш, дөяләр чүлдә су таба алу сәләтләренә дә ия – алар суны алтмыш чакрым ераклыктан тоялар.

Хуҗаларга дөяләре өчен махсус ризык әзерлисе түгел, чөнки алар үзләрен-үзе ашата ала. Моннан тыш, иреннәренең тиресе калын булуы чүлнең чәнечкеле, каты үләннәрен ашарга мөмкинлек бирә. Әгәр дөя су тапмаса, аңа ашаган үләннәрендәге сыеклык җитеп тора.

Дөяләр бик көчле җан ияләре. Ул үзенең авырлыгының яртысы кадәр йөкне күтәреп, көненә утыз-кырык



чакрым ераклыктагы араларны уза ала. Йөк күтәрмичә, фәкать кешене генә утыртып, дөя йөзләрчә чакрым юлны узарга сәләтле.

Элеккеге заманнарда дөяләрне хәрби максатларда да куллана торган иделәр. Әлеге җан ияләре уңайлы хәлдә төрле тарафка ята алалар. Моннан тыш, еш кына дөяләр бик зәһәр исле ашказаны сыекчасын төкерә торган булалар.

Дөяләрнең өстенлеге моның белән генә чикләнми. Әлеге җан ияләре хуҗалары өчен ризык чыганагы булып торган, чөнки аларның итләрен һәм сөтләрен туклану өчен, ә тиреләрен кием тегәр һәм йортлар төзер өчен кулланганнар. Сүз уңаеннан, дөя сөте бик куе һәм эсседә оеп төшмәве белән үзенчәлекле.

Югарыда әлеге җан иясенең күпме өстенлекләре барлыгын белдек. Нәкъ менә шуның өчен Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә дөяләр хакында фикер йөртергә һәм шул рәвешле Үзенең бөеклеге турында уйланырга чакыра.

## Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә дөяләр турында искә алынулар

Пәйгамбәребезнең атлана торган өч дөясе бар иде. Берсен сигез йөз акчага Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән уртаклашып алганнар иде. Исеме Фозул иде. Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылганда Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Бәкергә дүрт йөз акча бирде һәм дөяне үзенә алды. Ул дөягә атланып, Мәдинәгә китте. Икенче бер дөясе Җәзга атлы иде, аның колаклары киселгән иде. Атланып йөри торган өч дөядән башка сава торган егерме дөясе булды. Аларны һәр көн савалар иде. Тугыз дөя хатыннары өчен иде. Бер Сәкра атлы дөяне махсус Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзе өчен сава торган булдылар.

Шулай ук, риваятьләр буенча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Әл-Әдба исемле дөясе булганлыгы билгеле. Аллаһының Илчесе Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, андагы мөселманнарның һәрберсе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үз йортларына чакыра башлады. Берәү дә үпкәләмәсен өчен Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөя кемнең йорты каршында туктаса, шул кешедә кунак булырмын», – диде. Һәм дөя Әбү Әюб әл-Әнсари йорты каршында туктады. Бу йорт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәдинәдәге беренче йорты булды. Риваятьләргә караганда, Әл-Әдба бик шаян һәм җитез була, аны бер генә дөя дә чабышта уза алмый. Әмма берьюлы Мәдинәгә үзенең дөясе белән бер бәдәви гарәбе килә һәм оештырылган чабышларда аның дөясе барысыныкын да, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөясен дә узып китә. Сәхабәләрнең, Пәйгамбәребез иң җитез дөядә йөрми икән, дип күңелләре төшә. Әмма Расүлебез аларга елмаеп: «Дөреслектә, нәрсә генә югарылыкка күтәрелсә дә, Аллаһы аны түбәнлеккә төшерер», – дип әйтә.

Билгеле булганча, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кешеләргә үзара гына түгел, ә хайваннарга карата да мәрхәмәтле булырга кушкан.

Югарыда билгеләп үткәнчә, дөяләр гарәпләрдә бик киң таралган йорт хайваннары булганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга дөяләренә карата миһербанлы булырга: тәрбияләргә, ашатырга һәм авыр эшләр белән газапламаска куша. Бер хәдистә килә: «Берьюлы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына күзләреннән яшь аккан дөя килә. Пәйгамбәребез янәшәсендә булучыларга карап: «Бу кемнең дөясе?» – дип сорый. Әнсарлардан булган бер егет минем хайваным, дип җавап бирә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу егеткә шелтә ясый. Чынлыкта, дөя Пәйгамбәребезгә, күп эшләтә һәм начар ашата, дип үзенең хуҗасыннан зарланган була».

Икенче юлы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик ябык һәм йоннары коелган дөяне күрә. Аллаһының Илчесе аның хуҗасына шелтә ясап, болай дип әйтә: «Бу телсез җан ияләренә карата мөнәсәбәттә Аллаһыдан куркыгыз. Сез аларга утырып йөрисез һәм өсләрендә йөкләр ташыйсыз, соңрак итләрен ашап, йоннарын кулланасыз».

Сәфәргә җыенучы кешеләргә мөрәҗәгать итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә торган булган: «Әгәр сезнең юлыгыз үләннәр үсә торган җирдән узса, туктап хайваннарыгызны иркенләп, тукланганчы ашатыгыз, ә ризык булмаган урыннардан үткәндә, адымнарыгызны тизләтегез һәм дөяләрегез тәмам хәлдән тайганчы, ашарга ризык булган җиргә килеп өлгерергә тырышыгыз».

Күрүебезчә, дөяләр, чыннан да, бәяли белгән халыклар өчен, Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы булганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм адәм балаларына, әлеге җан ияләрен йорт хайваннары сыйфатында куллана алыр өчен, аларга карата миһербанлы һәм яхшы мөнәсәбәттә булырга кушкан.

■ Islam-today.ru

# «АЗАН» РАДИОСЫ ТАПШЫРУЛАРЫ ҖӘДВӘЛЕ

«Безне radioazan.ru сайтында яки Play Market һәм App Store’дан йөкләп алынган «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз».

## ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

## ҖОМГА

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Җомга тәбриге |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

## ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Миһербанлы җаннар |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Миһербанлы җаннар |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Миһербанлы җаннар |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Миһербанлы җаннар |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |




# Шәкертләр һәм фәнни җитәкчеләр өчен кулланма нәшер ителде

ТР мөселманнары Диния нәзарәте, «Хозур» нәшрият йорты «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре белән берлектә шәкертләр һәм фәнни җитәкчеләр өчен «Дини һөнәри уку йортларында мөстәкыйль һәм фәнни эшчәнлекне оештыру» дип аталган кулланма нәшер итте. Әлеге кулланма урта һөнәри дини белем бирү мәдрәсәләрендә уку-укыту процессына ярдәмлек буларак төзелде. Шулай ук чыгарылыш квалификация эшен язганда эзләнүләрне җыеләйтү максатыннан, кушымталарда диаграммалар, презентацияләр үрнәкләре дә бирелә. Бу кулланма фәнни тикшерену эшчәнлеген гамәлдә тормышка ашырырга ярдәм итәчәк.

- **Кибетләрнең адреслары:**
  - Тукай урамы, 36 йорт;
  - Газовая урамы, 14 йорт.
- **Белешмәләр өчен телефон:**
  +7 (903) 388-86-33.




## КАЗАН ӨЧЕН СЕНТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.09.2019 | 02:20 | 03:17 | 04:47 | 12:00 | 16:24 | 18:38 | 20:33 |
| 02.09.2019 | 02:23 | 03:18 | 04:48 | 12:00 | 16:22 | 18:36 | 20:30 |
| 03.09.2019 | 02:27 | 03:20 | 04:50 | 12:00 | 16:20 | 18:33 | 20:27 |
| 04.09.2019 | 02:30 | 03:22 | 04:52 | 12:00 | 16:18 | 18:31 | 20:23 |
| 05.09.2019 | 02:33 | 03:24 | 04:54 | 12:00 | 16:16 | 18:28 | 20:20 |
| 06.09.2019 | 02:36 | 03:26 | 04:56 | 12:00 | 16:14 | 18:26 | 20:17 |
| 07.09.2019 | 02:39 | 03:28 | 04:58 | 12:00 | 16:12 | 18:23 | 20:13 |
| 08.09.2019 | 02:42 | 03:30 | 05:00 | 12:00 | 16:10 | 18:20 | 20:10 |
| 09.09.2019 | 02:45 | 03:32 | 05:02 | 12:00 | 16:08 | 18:18 | 20:07 |
| 10.09.2019 | 02:48 | 03:34 | 05:04 | 12:00 | 16:06 | 18:15 | 20:04 |
| 11.09.2019 | 02:51 | 03:36 | 05:06 | 12:00 | 16:04 | 18:12 | 20:01 |
| 12.09.2019 | 02:53 | 03:38 | 05:08 | 12:00 | 16:01 | 18:10 | 19:57 |
| 13.09.2019 | 02:56 | 03:40 | 05:10 | 12:00 | 15:59 | 18:07 | 19:54 |
| 14.09.2019 | 02:59 | 03:42 | 05:12 | 12:00 | 15:57 | 18:05 | 19:51 |
| 15.09.2019 | 03:01 | 03:44 | 05:14 | 12:00 | 15:55 | 18:02 | 19:48 |
| 16.09.2019 | 03:04 | 03:45 | 05:15 | 12:00 | 15:53 | 17:59 | 19:45 |
| 17.09.2019 | 03:07 | 03:47 | 05:17 | 12:00 | 15:51 | 17:57 | 19:42 |
| 18.09.2019 | 03:09 | 03:49 | 05:19 | 12:00 | 15:48 | 17:54 | 19:39 |
| 19.09.2019 | 03:12 | 03:51 | 05:21 | 12:00 | 15:46 | 17:51 | 19:36 |
| 20.09.2019 | 03:14 | 03:53 | 05:23 | 12:00 | 15:44 | 17:49 | 19:33 |
| 21.09.2019 | 03:17 | 03:55 | 05:25 | 12:00 | 15:42 | 17:46 | 19:30 |
| 22.09.2019 | 03:19 | 03:57 | 05:27 | 12:00 | 15:40 | 17:43 | 19:27 |
| 23.09.2019 | 03:21 | 03:59 | 05:29 | 12:00 | 15:37 | 17:41 | 19:24 |
| 24.09.2019 | 03:24 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 15:35 | 17:38 | 19:21 |
| 25.09.2019 | 03:26 | 04:03 | 05:33 | 12:00 | 15:33 | 17:36 | 19:18 |
| 26.09.2019 | 03:29 | 04:05 | 05:35 | 12:00 | 15:31 | 17:33 | 19:15 |
| 27.09.2019 | 03:31 | 04:07 | 05:37 | 12:00 | 15:28 | 17:30 | 19:13 |
| 28.09.2019 | 03:33 | 04:09 | 05:39 | 12:00 | 15:26 | 17:28 | 19:10 |
| 29.09.2019 | 03:35 | 04:11 | 05:41 | 12:00 | 15:24 | 17:25 | 19:07 |
| 30.09.2019 | 03:38 | 04:13 | 05:43 | 12:00 | 15:22 | 17:22 | 19:04 |

**Игълан!**

**"Хозур ТВ" телеканалына тапшырулар мөхәррире, видеомонтаж режиссеры, PR бүлеге хезмәткәре таләп ителә.**

**Резюмены биредәге адрес буенча җибәрегез: huzurtv@huzur.ru**

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Август саны, №8 (289)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2752
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 27 нче августта таратыла.
График буенча бу санга 26 нчы август көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.